ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «11» гыйнвареннән № 2

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 112 номерлы карарына (2020 елның 21 сентябреннән 234 номерлы, 2022 елның 14 февраленнән 53 номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «2023 елның 1 гыйнварыннан бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын арттыру турында» 2022 елның 09 августындагы 03-16/5605 номерлы рекомендация хаты нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 112 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш хисапчы) | | 25 500 |
| Бүлек башлыгы | 21 700 | 21 700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 19 300 | 19 300 |
| Хисапчы | 18 000 | 18 000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә кертү шарты булып, структурада кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 112 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмәнең 3 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Хезмәткәр эштән киткән очракта, агымдагы елда бер тапкыр бирелә торган түләү хисапланмый һәм түләнми.

Беренче елда еллык түләүле отпуск бирелгәндә хезмәткәргә бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабре буенча эшкә кергән көннән исәпләнә.».

3. Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге үлчәмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 19 700 | 21 000 |
| Хисапчы | | 18 500 |

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының штат расписаниесенә хисапчы вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше тора.».

4. Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктының 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Хезмәткәр эштән киткән очракта, агымдагы елда бер тапкыр бирелә торган түләү хисапланмый һәм түләнми.

Беренче елда еллык түләүле отпуск биргәндә бухгалтерларга бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елында башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабре буенча эшкә кергән көннән исәпләнә.».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәче в.б. Л.К. Исхакова